БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«02» 08 2021 г. № 223

Ташландык суларны чыгару үзәкләштерелгән системасына һәм чистарту корылмаларына килә торган агып җыелган суларда пычраткыч матдәләрнең рөхсәт ителгән концентрацияләре нормативлары турында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны чыгару турында» 2011 елның 7 июлендәге 416-ФЗ номерлы Федераль Закон нигезендә, шулай ук «Агып җыелган суларның составын һәм үзлекләрен контрольдә тотуны гамәлгә ашыру кагыйдәләрен раслау турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының үз көчләрен югалтуын тану һәм аларга үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 22 маендагы 728 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары 2020 елның 1 июленнән үз көченә керүгә, шулай ук «Салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны чыгару кагыйдәләрен раслау турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2013 елның 29 июлендәге 644 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына үзгәрешләр кертүгә бәйле рәвештә, су объектларын пычранудан саклау максатларында, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Балтач муниципаль районында предприятиеләрдән һәм оешмалардан ташландык суларны чыгару үзәкләштерелгән системасына һәм «Балтач торак-коммуналь хуҗалыкның күптармаклы җитештерү предприятиесе» АҖнең чистарту корылмаларына керә торган агып җыелган сулардагы пычраткыч матдәләрнең рөхсәт ителгән концентрациясе нормативларын әлеге карарның кушымтасы нигезендә расларга.

2. Күрсәтелгән нормативлар күпфатирлы йортлар белән идарә итүне гамәлгә ашыра торган оешмаларга (әлеге абонентлардан биологик чистарту корылмаларына килә торган агып җыелган суларның мөмкин булган иң чик концентрацияләренә нормативлар билгеләнми) кагылмый.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2020 елның 1 июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. «Балтач торак-коммуналь хуҗалыкның күптармаклы җитештерү предприятиесе» АҖенә ташландык суларны чыгару үзәкләштерелгән системасына һәм чистарту корылмаларына Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы предприятиеләре һәм оешмалары тарафыннан ташлана торган агып җыелган суларның билгеләнгән нормативларга туры килүен планлы һәм планнан тыш контрольдә тотуны тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы И. С. Галимуллин

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
2021 елның «02» 08
223 номерлы карарына
кушымта

Ташландык суларны чыгару үзәкләштерелгән системалары эшенә тискәре йогынтыны булдырмау максатында билгеләнгән, абонентларның агып җыелган суларында пычраткыч матдәләрнең рөхсәт ителгән концентрациясе нормалары

| Пычраткыч матдәнең исеме | Тулаем алганда агып җыелган суларның күрсәткеченең һәм (яисә) концентрациясенең мөмкин булган зурлыгы, мг/дм3 |
|---|---|
| Алюминий | 5 |
| 5 көндә кислородны биохимик куллану (БПК$_5$) | 300 |
| Үлчәнгән матдәләр | 300 |
| Тимер | 5 |
| Марганец | 1 |
| Бакыр | 1 |
| Нефть продуктлары | 10 |
| Синтетик өске-актив матдәләр (СПАВ) | 10 |
| Сульфатлар | 1000 |
| Фенол | 5 |
| Гомуми фосфор | 12 |
| Хлорид | 1000 |
| Цинк | 1 |
| | |

Искәрмә:

- Нефть продуктларын эретелгән эмульгацияләнгән хәлдә генә ташларга рөхсәт ителә.